**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ ШЕШМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

ул.Комарова, д.14, с.Шешминская Крепость, 423104

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**ШЕШМИНКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

Комаров урамы, 14 йорты, Шешминка Крепосте авылы, 423104

тел./факс(84396) 2-36-54 email: Shesh.Cmn2@tatar.ru

№112 26.12.2024 ел

**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**Шешминка авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Шешминка авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2020 елның 26 октябрендәге №7 карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Шешминка авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Шешминка авыл җирлеге Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Шешминка авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2020 елның 26 октябрендәге № 7 карарына (Советның 2023 елның 18 сентябрендәге 76 номерлы, 2024 елның 28 октябрендәге 101 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 статьяда:

- 2 абзацта «кадастр хакыннан» сүзләрен төшереп калдырырга.
- 2 статьяның 4 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә: «4) шәхси ярдәмче хуҗалык, бакчачылык яисә яшелчәчелек алып бару өчен сатып алынган (бирелгән) эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланылмый торган җир кишәрлекләренә, шулай ук «Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган гомуми билгеләнештәге җир кишәрлекләренә карата 0,15%, әлеге абзацта

күрсәтелгән җир кишәрлекләреннән тыш, аларның һәрберсенең кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып китә;»

1.2. 3 статьяда:

- 3 пунктта «каты көнкүреш калдыклары полигоннары» сүзләрен «калдыкларны саклау объектлары» сүзләренә алмаштырырга.

1.3. 4 статьяда:

- 4 статьяның исемен яңа редакциядә бәян итәргә «4 Статья. Юридик зат салым түләүчеләр тарафыннан салым түләү тәртибе».

- түбәндәге эчтәлекле пункт өстәргә: «Хисап чоры квартал буларак билгеләнгән салым түләүчеләр агымдагы салым чорының беренче, икенче һәм өченче кварталлары тәмамланганнан соң салым буенча аванс түләүләре суммаларын җир кишәрлегенең кадастр хакының процент өлешенең тиешле салым ставкасының дүрттән бере итеп исәплиләр.».

1.4. 5,6 статьяларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карар 2025 елның 01 гыйнварыннан, әмма рәсми басылып чыккан көненнән кимендә бер ай узгач үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Шешминка авыл җирлеге
башлыгы, Совет рәисе А.В.Сидоров